КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 11 март г.Казань № 197

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 февраль, 105 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2017 ел, 26 май, 307 нче; 2018 ел, 12 декабрь, 1117 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 26 сентябрь, 877 нче; 2020 ел, 12 июнь, 485 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2022 ел, 18 гыйнвар, 21 нче; 2022 ел, 6 декабрь, 1291 нче; 2023 ел, 18 февраль, 154 нче; 2024 ел, 2 июль, 495 нче; 2024 ел, 4 октябрь, 858 нче; 2024 ел, 16 декабрь, 1148 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә, 1.2 пункттагы беренче абзацында «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документациясенең унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртибләрен раслау турында» 2014 елның 15 декабрендәге 834н номерлы боерыгы белән расланган 070/у номерлы форма буенча Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Авыруларны медицина нигезендә сайлап алу һәм шифаханә-курорт дәвалануына

җибәрү тәртибе турында» 2004 елның 22 ноябрендәге 256 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә бирелгән белешмә кәгазе белән расланган шифаханә-курорт дәвалануына мохтаҗлык турында» сүзләрен «һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документациясенең унификацияләнгән формаларын һәм аларны алып бару тәртибләрен раслау турында» 2025 елның 13 маендагы 274н номерлы боерыгы белән расланган 070/у номерлы форма буенча белешмә кәгазе белән расланган шифаханә-курорт дәвалавы өчен зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре булмау турында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин